РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«29» декабрь 2021 с. Тюлячи № 323

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы халкы өчен 2022 елга торак хезмәтләренә тарифлар турында

Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарының 2021 елның 24 декабрендәге хатын карап, Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2006 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 09 апрелендәге «Халыкка күрсәтелә торган торак һәм коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту һәм алар өчен түләү күләменең нигезлелеген арттыру чаралары турында» 250 номерлы карары, «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә халык хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау системасының нәтиҗәлелеген арттыру чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 19 февралендәге 85 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның 1 гыйнварыннан расларга һәм гамәлгә кертергә:

- социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен торак урынны карап тоткан һәм ремонтлаган өчен түләү күләме һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән милекчеләр өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме, 1 номерлы кушымта нигезендә;

- район халкы өчен коммуналь хезмәтләргә тарифлар, 2 номерлы кушымта нигезендә.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Ф.С. Вәлиевка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«29» 12 2021 № 323
карарына 1 номерлы кушымта

2022 елга район халкы өчен торак хезмәтләренә тарифлар

| Хезмәт исеме | Үлчәү берәмлеге | Гамәлдә булу вакыты 01.01.2022 елдан 30.06.2022 елга кадәр (сум) | Гамәлдә булу вакыты 01.07.2022 елдан 31.12.2022 елга кадәр (сум) |
|---|---|---|---|
| Халык өчен | | | |
| 1. Торак фонды белән идарә итү | $м^2$ | 3,70 | 3,93 |
| 2. Торак бинаны агымдагы ремонтлау | $м^2$ | 3,58 | 3,80 |
| 3. Йорт эчендәге сантехник челтәрләрне агымдагы ремонтлау | $м^2$ | 2,39 | 2,53 |
| 4. Газүткәргечнең йорт эчендәге челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | $м^2$ | 0,37 | 0,39 |
| 5. Йорт эчендәге электр белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау | $м^2$ | 1,36 | 1,44 |
| 6. Гомумйорт су белән тәэмин итү системаларына агымдагы ремонт | $м^2$ | 0,54 | 0,57 |
| 7. Йорт яны территориясен җыештыру | $м^2$ | 3,90 | 4,14 |
| 8. Дератизация | $м^2$ | 0,13 | 0,14 |

Сыек хуҗалык калдыкларын чыгару буенча хезмәтләрнең бер кешегә тәкъдим ителә торган бәясе 01.01.2022 елдан – 132,64 сум/айга, 01.07.2022 елдан – 145,90 сум/айга.

Эшләр идарәчесе И.Т. Һадиев

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«29» 12 2021 № 323
карарына 2 номерлы кушымта

2022 елга район халкы өчен коммуналь хезмәтләргә тарифлар

| Хезмәт исеме | Үлчәү берәмлеге | Гамәлдә булу вакыты 01.01.2022 елдан 30.06.2022 елга кадәр (сум) | Гамәлдә булу вакыты 01.07.2022 елдан 31.12.2022 елга кадәр (сумнарда) |
|---|---|---|---|
| Халык өчен | | | |
| 1. Бер юу өчен мунча хезмәте | кеше | 100 | 100 |

Эшләр идарәчесе И.Т. Һадиев